КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 5 август г.Казань № 555

Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары үз көчен югалтуны тану турында» 2013 ел, 27 июнь, 543 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 август, 555 нче карары белән расланды

**Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Әлеге Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру процедурасын регламентлаштыра (алга таба – төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)).

2. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) максаты Татарстан Республикасы территориясендә җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә законнар белән билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, билгеләү һәм аларга юл куймаудан гыйбарәт.

3. Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы булып Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тора.

4. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәгеләр ярдәмендә гамәлгә ашырыла:

а) юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүләр;

б) юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне үтәүне системалы рәвештә күзәтүләр, мәҗбүри таләпләрне үтәү торышын анализлау һәм фаразлау, шулай ук җайга алына торган тармакларда бәяләр (тарифлар) мониторингы;

в) юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең билгеләнгән тәртиптә расланган мәгълүмат бирүнең формаларын һәм (яки) вакыттан вакытка булуын куллануны үзгәртү турында үтенеч язуларын карап тикшерүләр (мәгълүматны ачу стандартларын саклау өлешендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда);

г) дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны җайга сала торган законнар нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалауга юнәлтелгән чаралар оештыру һәм үткәрү;

д) билгеле булган бозулар нәтиҗәләрен кисәтү һәм (яки) бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чаралар күрү.

5. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә законнар белән билгеләнгән җайга салына торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты булып тора.

6. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы түбәндәгеләр:

электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү, су агызу, табигый монополияләр субъектлары, коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәләрендә җайга сала торган бәяләр (тарифлар), шулай ук дәүләт җайга салырга тиешле товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) җайга сала торган бәяләр (тарифлар, өстәмәләр, өстәлгән хаклар һ.б.ш.), каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә бәя кую һәм тарифларны куллану тәртибен билгеләүгә һәм (яки) куллануга таләпләрне үтәү;

газ бүлү челтәрләре буенча газ илтүне гамәлгә ашыручы табигый монополияләр, электр энергиясен күпләп һәм ваклап сату базарлары субъектлары, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәре оешмалары, коммуналь комплекс оешмалары, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча төбәк операторлары, каты көнкүреш калдыклары белән эш итү буенча операторлар, кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны тормышка ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларын үтәү;

электр энергетикасы һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәләрендә дәүләт җайга сала торган бәяләргә (тарифларга) кертелгән инвестиция ресурсларын файдалану.

7. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба – Рәис) һәм аның алар карамагында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре булган урынбасарлары;

б) Дәүләт комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның карамагында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре булган урынбасарлары;

в) Дәүләт комитетының структур бүлекчәләренең алар карамагында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре булган «белгечләр» категориясендәге әйдәүче һәм өлкән төркемнәр вазыйфаларындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре.

8. Төгәл бер тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар Рәис (Рәис урынбасары) боерыгы белән раслана.

9. Тикшерүләр үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерүләр үткәргәндә «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне сакларга һәм йөкләмәләрне башкарырга тиеш.

10. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар прокуратура органнары, эксперт оешмалары, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары, үзләре җайга салынучы оешмалар, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләре белән үзара бәйләнештә булалар.

11. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда административ процедуралар вакытлары һәм эзлеклелеге Дәүләт комитеты раслаган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентлары белән билгеләнә.

12. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрүгә, кирәк булганда, Рәис (Рәис урынбасары) боерыгы нигезендә тикшерелә торган контрольдәге субъектлар белән граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм аларның аффилирланган затлары булмаган аккредитацияләнгән экспертлар һәм эксперт оешмалары җәлеп ителә ала.

13 Дәүләт комитетының төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

14. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте порталында Дәүләт комитеты сайтында урнаштырыла.